проект

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
Комитета Государственного Совета Республики Татарстан
по образованию, культуре, науке и национальным вопросам

О внесении в Государственный Совет Республики Татарстан проекта закона Республики Татарстан «О театрах и театральном деле в Республике Татарстан»

Рассмотрев и обсудив проект закона Республики Татарстан «О театрах и театральном деле в Республике Татарстан», Комитет ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. В соответствии со статьей 76 Конституции Республики Татарстан внести указанный законопроект в Государственный Совет Республики Татарстан.

2. Докладчиком по проекту закона Республики Татарстан «О театрах и театральном деле в Республике Татарстан» на заседании Государственного Совета Республики Татарстан определить председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам Р.И. Валеева.

Председатель Комитета Р.И. Валеев

Проект
вносится Комитетом
Государственного Совета
Республики Татарстан
по образованию, культуре, науке
и национальным вопросам

**Закон Республики Татарстан**

**О театрах и театральном деле в Республике Татарстан**

Статья 1. **Предмет правового регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон направлен на регулирование вопросов деятельности театров в Республике Татарстан в пределах полномочий органов государственной власти Республики Татарстан.

2. Законодательство Республики Татарстан о театрах и театральном деле основывается на соответствующих положениях Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, федеральных законов, иных нормативных правовых актов Российской Федерации и состоит из настоящего Закона и принимаемых в соответствии с ним нормативных правовых актов Республики Татарстан.

Статья 2. **Государственная политика Республики Татарстан в сфере театрального дела**

Государственная политика Республики Татарстан в сфере театрального дела направлена на решение следующих задач:

1) создание условий для развития театрального искусства, сохранение и развитие татарской, русской драматургии и национальной драматургии других народов;

2) расширение доступности театрального искусства для различных групп населения, увеличение зрительской аудитории театров;

3) поддержка театров на территории Республики Татарстан, совершенствование их материально-технической базы, механизмов самоорганизации театров;

4) кадровое обеспечение театральной деятельности, соответствующее современным требованиям.

Статья 3. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере театрального дела**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в сфере театрального дела относятся:

1) законодательное регулирование отношений в сфере организации

театрального дела в Республике Татарстан;

2) осуществление контроля за соблюдением и исполнением законов Республики Татарстан в сфере театрального дела;

3) осуществление иных полномочий, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере театрального дела относятся:

1) издание нормативных правовых актов по вопросам регулирования театрального дела;

2) утверждение государственных программ поддержки и развития театрального искусства в Республике Татарстан;

3) принятие решений о создании, реорганизации и ликвидации государственных театров Республики Татарстан в порядке, установленном законодательством Российской Федерации;

4) создание экономических и организационных условий для деятельности театров в Республике Татарстан;

5) утверждение порядка установления льгот для отдельных категорий граждан при посещении государственных театров Республики Татарстан;

6) осуществление иных полномочий в сфере театрального дела в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

3. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области культуры, относятся:

1) осуществление функций и полномочий учредителя государственных театров Республики Татарстан;

2) подготовка предложений Кабинету Министров Республики Татарстан о создании, реорганизации и ликвидации государственных театров Республики Татарстан;

3) ведение реестра театров Республики Татарстан;

4) обеспечение условий доступности государственных театров Республики Татарстан для инвалидов;

5) иные полномочия в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

Статья 4. **Государственная поддержка в сфере театрального дела**

Органы государственной власти Республики Татарстан осуществляют в соответствии с законодательством Российской Федерации государственную поддержку театров в Республике Татарстан, в том числе посредством:

1) содействия в осуществлении инвестиционных проектов в целях сохранения, возрождения и развития театров в Республике Татарстан;

2) содействия материально-техническому обеспечению деятельности театров в Республике Татарстан;

3) поддержки участия творческих коллективов (трупп) театров независимо от их организационно-правовой формы в культурных мероприятиях республиканского, межрегионального, общероссийского и международного уровней;

4) оказания информационной поддержки театрам;
5) содействия обучению и подготовке квалифицированных специалистов;
6) содействия в создании новых театральных постановок;
7) иных мероприятий, проводимых в соответствии с законодательством Российской Федерации.

Статья 5. **Театры в Республике Татарстан**

1. В зависимости от формы собственности на территории Республики Татарстан функционируют и могут быть созданы следующие театры:
1) государственные;
2) муниципальные;
3) негосударственные.
2. Театры в Республике Татарстан в соответствии со своими учредительными документами могут осуществлять деятельность, не запрещенную законодательством Российской Федерации и соответствующую целям деятельности театров.
3. Государственные театры Республики Татарстан создаются в форме учреждений для осуществления театральной деятельности в целях удовлетворения и формирования духовных потребностей зрителей в сценическом искусстве, а также развития театрального искусства.
4. Государственные театры Республики Татарстан в соответствии со своими учредительными документами могут осуществлять приносящую доходы деятельность лишь постольку, поскольку это служит достижению целей деятельности театров, предусмотренных частью 3 настоящей статьи.

Статья 6. **Реестр театров Республики Татарстан**

1. В целях учета театров, постоянно действующих на территории Республики Татарстан, органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области культуры, ведется реестр театров Республики Татарстан (далее - реестр). Данные реестра используются при разработке государственной программы Республики Татарстан поддержки и развития театрального искусства.
2. Внесение сведений в реестр и его ведение осуществляются в соответствии с Положением о реестре театров Республики Татарстан, которое утверждается органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области культуры.
3. Исключение из реестра производится в случае ликвидации театра.

Статья 7. **Виды деятельности театров**

Основными видами деятельности театра являются:
1) создание и показ спектаклей, театральных представлений, организация гастролей, концертов, проведение творческих вечеров, фестивалей и конкурсов;
2) подготовка на основе договоров с организациями и гражданами театральных постановок, театральных представлений, других мероприятий для показа на их

собственных или арендованных ими сценических площадках, по телевидению, для трансляции по радио, интернет-трансляции, съемок на кино-, фото-, видео- и иные материальные носители при соблюдении прав авторов и исполнителей ролей (партий) в соответствии с законодательством Российской Федерации;

3) проведение стажировок работников творческих театральных профессий ведущими мастерами и деятелями театра;

4) предоставление организациям на основе договоров постановочных услуг, сценическо-постановочных средств для проведения театральных постановок, театральных представлений, других мероприятий;

5) изготовление по заказам организаций и граждан предметов художественного оформления театральных постановок, театральных представлений, других мероприятий;

6) предоставление в порядке, установленном законодательством Российской Федерации, своих сценических площадок другим театрам для проведения гастрольных и выездных мероприятий, совместных театральных проектов и программ;

7) подготовка, тиражирование и реализация информационно-справочных и рекламных материалов, копий кино-, фото-, видеоматериалов и фонограмм, связанных с художественно-творческой деятельностью театра, при соблюдении прав авторов и исполнителей ролей (партий) в соответствии с гражданским законодательством;

8) предоставление в прокат и реализация костюмов, обуви, оборудования, реквизита, бутафории, гримерных и иных принадлежностей в порядке, установленном законодательством Российской Федерации;

9) реализация билетов на мероприятия театра, а также сопутствующих услуг, предоставляемых зрителям;

10) создание и демонстрация экспозиции предметов, связанных с историей и деятельностью театра;

11) иные виды деятельности, соответствующие предмету и целям деятельности театра, не запрещенные законодательством Российской Федерации.

### Статья 8. **Права и обязанности театров**

1. В соответствии с законодательством Российской Федерации театры имеют право самостоятельно:

1) выбирать репертуар и художественное направление своей деятельности;

2) планировать свою деятельность и определять перспективы развития исходя из собственных творческих и хозяйственных ресурсов и необходимости творческого и социального развития;

3) устанавливать цены (тарифы) на платные услуги и продукцию, реализуемые театром;

4) устанавливать режим работы театра и правила внутреннего трудового распорядка;

5) осуществлять иные права, предусмотренные законодательством Российской Федерации.

2. Театры вправе иметь собственную символику – эмблемы, гербы, иные геральдические знаки, флаги и гимны, описание которой должно содержаться в учредительных документах.

3. Театры в Республике Татарстан, осуществляющие публичное исполнение и (или) публичный показ театральных представлений, обязаны:

1) обеспечивать во время театрального представления охрану жизни и здоровья зрителей, а также их имущества, принятого на хранение;

2) размещать для всеобщего обозрения в местах продажи билетов и в местах публичного исполнения и (или) публичного показа театрального представления афишу с указанием полного наименования произведения, лежащего в ее основе, его автора, имен постановщиков и исполнителей главных ролей (партий), а также других сведений по усмотрению театра;

3) предоставлять зрителям информацию о месте проведения, времени начала и окончания театрального представления, о ценах на билеты, условиях их приобретения и возврата, о льготах, предусмотренных для определенных категорий зрителей, возрастных ограничениях на посещение театрального представления;

4) указывать на театральном билете стоимость услуги, наименование театра, его организационно-правовую форму, название театрального представления, место, дату и время его показа, место в зрительном зале.

4. Тексты афиш, другой наглядной информации оформляются на государственных языках Республики Татарстан.

5. В целях информирования граждан возле театральных касс размещается актуальная информация о наличии билетов на спектакли.

6. В театрах обеспечиваются условия доступности для инвалидов предоставляемых услуг в соответствии с законодательством Российской Федерации о социальной защите инвалидов.

7. Театры могут обеспечивать сопровождение театральных представлений субтитрированием либо синхронным переводом на государственные языки Республики Татарстан, а также другие языки. Информирование граждан о предоставляемых услугах должно осуществляться до приобретения ими билетов в порядке, установленном администрацией театра.

Статья 9. **Льготы при посещении театров**

1. При организации платных мероприятий театры могут устанавливать льготы для детей дошкольного возраста, обучающихся, инвалидов, военнослужащих, проходящих военную службу по призыву, иных категорий граждан.

2. Порядок установления льгот для отдельных категорий граждан при посещении государственных театров Республики Татарстан утверждается Кабинетом Министров Республики Татарстан, для муниципальных театров – соответствующим органом местного самоуправления. Иные театры вправе самостоятельно устанавливать льготы для посещения зрителями спектаклей, концертов и иных мероприятий.

Статья 10. **Финансирование театров**

1. Финансирование театров в Республике Татарстан может осуществляться за счет:

1) средств федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан и бюджетов муниципальных образований в Республике Татарстан;

2) доходов театров в Республике Татарстан, полученных от осуществления ими в установленном порядке приносящей доход деятельности;

3) пожертвований и иных безвозмездных поступлений от физических и юридических лиц;

4) иных источников, не запрещенных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

2. Размеры бюджетного финансирования государственных театров Республики Татарстан определяются в соответствии с законодательством Республики Татарстан.

3. Кабинетом Министров Республики Татарстан может быть принято решение о государственной поддержке негосударственных театров, включенных в реестр.

Статья 11. **Аттестация профессиональных творческих работников государственных театров Республики Татарстан**

1. К профессиональным творческим работникам государственного театра Республики Татарстан относятся художественный персонал театра и творческий состав театра (труппа).

2. С целью повышения эффективности деятельности, обеспечения качественной подготовки театральных постановок, рационального отбора кадров в государственных театрах Республики Татарстан проводится аттестация профессиональных творческих работников, во время которой оцениваются творческий уровень, профессиональные качества, возможность дальнейшей деятельности данных работников в соответствии с перспективным и текущим планами работы государственного театра Республики Татарстан.

3. Аттестация профессиональных творческих работников государственных театров Республики Татарстан осуществляется в порядке и с периодичностью, установленными Положением об аттестации, утвержденным в театре.

Типовое положение об аттестации творческих работников утверждается органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области культуры.

Статья 12. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан

**Пояснительная записка**
**к проекту закона Республики Татарстан**
**«О театрах и театральном деле в Республике Татарстан»**

Рабочей группой, образованной распоряжением Председателя Государственного Совета Республики Татарстан, в целях законодательного регулирования деятельности театров в Республике Татарстан разработан проект закона Республики Татарстан «О театрах и театральном деле в Республике Татарстан».

Законопроект определяет государственную политику Республики Татарстан в сфере театрального дела, устанавливает основы деятельности театров в Республике Татарстан, меры их государственной поддержки.

В проекте закона дано распределение полномочий органов государственной власти Республики Татарстан в сфере театрального дела между Государственным Советом Республики Татарстан, Кабинетом Министров Республики Татарстан и органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области культуры.

В целях учета театров, постоянно действующих на территории Республики Татарстан, предполагается ведение органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области культуры, реестра театров в Республике Татарстан. Данные реестра будут использованы при разработке государственных программ Республики Татарстан поддержки и развития театрального искусства.

С целью повышения эффективности деятельности, обеспечения качественной подготовки театральных постановок, рационального отбора кадров в государственных театрах Республики Татарстан вводится аттестация профессиональных творческих работников согласно Положению об аттестации работника, утвержденному в театре.

Законопроект устанавливает права и обязанности театров, в том числе информирование зрителей о театральных представлениях и наличии билетов на спектакли, а также предоставление льгот, предусмотренных для определенных категорий зрителей.

Таким образом, законопроект позволит сформировать эффективный механизм регулирования отношений в сфере театрального дела в Республике Татарстан.

**Перечень**
**законодательных актов Республики Татарстан, подлежащих признанию утратившими силу, приостановлению, изменению или принятию в связи с принятием закона Республики Татарстан**
**«О театрах и театральном деле в Республике Татарстан»**

В связи с принятием закона Республики Татарстан «О театрах и театральном деле в Республике Татарстан» признания утратившими силу, приостановления, изменения или принятия законодательных актов Республики Татарстан не потребуется.

**Финансово-экономическое обоснование**
**к проекту закона Республики Татарстан**
**«О театрах и театральном деле в Республике Татарстан»**

Проектом закона Республики Татарстан «О театрах и театральном деле в Республике Татарстан» не вводятся положения, требующие дополнительного финансирования за счет средств бюджета Республики Татарстан.

Проект

**Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законның хокукый җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында театрлар эшчәнлегенең нигезләрен, аларга дәүләт ярдәме чараларын, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасында театр эше өлкәсендәге вәкаләтләрен билгели.

2. Театрлар һәм театр эше турындагы законнар Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, “Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре” 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законының, федераль законнарның, “Мәдәният турында” 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының тиешле нигезләмәләренә таяна һәм әлеге Законнан һәм аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларыннан гыйбарәт.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) театр – тамашачыларның сәхнә сәнгатенә булган рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм булдыру, шулай ук театр сәнгатен үстерү максатларында театр эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма;

2) театр эше – театр эшчәнлеген башкаруны тәэмин итә торган оешкан икътисадый система, шул исәптән дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм гражданнарның театр сәнгате әсәрләрен (сәхнә әсәрләрен) язу, халык алдында башкару һәм (яисә) халыкка күрсәтү, тарату һәм саклау, театр иҗатын, һөнәри белемне, фәнне, театр журналистикасын, театр сәнгате тарихы, теориясе һәм практикасы буенча нәширлек эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыруны тәэмин итү, һөнәри кадрларны әзерләү, театр сәнгатенең иң яхшы үрнәкләрен пропагандалау белән бәйле эшчәнлек;

3) театр эшчәнлеге – спектакльләр кую һәм (яисә) күрсәтү өчен башкарыла торган эшчәнлек;

4) театр сәнгате – театрның сәхнә әсәрләрен кабатланмас ясаучы аерым үзенчәлекләргә ия башкару сәнгате төре, аның максатын чынбарлыкны (тормышны, характерларны, вакыйгаларны һәм башка күренешләрне), артистларның тамашачылар каршында төрле рәвешләрдә (драма, музыкаль, курчак, күләгә театры һәм башкалар) сәхнәдә эшләүләре (уйнаулары) аркылы сәхнә әсәрен халык алдында башкарып һәм (яисә) халыкка күрсәтеп, сәнгати чагылдыру, аны аңлату һәм бәяләү тәшкил итә.

2. Әлеге законда кулланыла торган башка төшенчәләр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланылалар.

3 статья. **Татарстан Республикасының театр эше өлкәсендәге дәүләт сәясәте**

Татарстан Республикасының театр эше өлкәсендәге дәүләт сәясәте түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлтелгән:

1) театр сәнгатен үстерү, татар, рус драматургиясен һәм башка халыкларның милли драматургияләрен саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруны;

2) төрле халык төркемнәренең театр сәнгатеннән файдалану мөмкинлекләрен киңәйтүне, театрларның тамашачылар аудиторияләрен арттыруны;

3) Татарстан Республикасы территориясендә театрларга ярдәм итүне, аларның матди-техник базаларын, театрларның мөстәкыйль оешу механизмнарын камилләштерүне;

4) театр белгечләренең һөнәри осталыкларын арттыруга.

4 статья. **Театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында театр эшен оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) театр эшен җайга салу мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар чыгару;

2) Татарстан Республикасында театр сәнгатенә ярдәм итүнең һәм аны үстерүнең дәүләт программаларын эшләү һәм раслау;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт театрларын төзү, үзгәртеп төзү һәм ябу турында карар кабул итү;

4) Татарстан Республикасы театрларының эшчәнлеге өчен икътисадый шартлар һәм аны оештыру өчен шарлар тудыру;

5) аерым категорияләрдәге гражданнарга Татарстан Республикасы дәүләт театрларына баруга ташламалар бирү тәртибен билгеләү;

6) Татарстан Республикасы дәүләт театрларыннан инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү;

7) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә театр эше өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт театрлары эшчәнлеген координацияләү;

2) Татарстан Республикасында театрлар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен билгеләү;

3) Татарстан Республикасында театрлар реестрын алып бару;

4) Татарстан Республикасы дәүләт театрларын төзү, үзгәртеп төзү һәм ябу турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдимнәрен әзерләү;

5) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр.

5 статья. **Театр эше өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль театрларны һәм театр сәнгатен үстерү буенча муниципаль программалар эшләргә һәм гамәлгә ашырырга;

2) үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль театрларны гамәлгә куючы функцияләрен башкарырга;

3) Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә театрларны оештыру һәм театр сәнгатен үстерү өчен шартлар тудырырга;

4) муниципаль театрлардан инвалидларның файдала алуын тәэмин итәргә;

5) Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

6 статья. **Театр эше өлкәсендә дәүләт ярдәме**

1. Театр эшенә дәүләт ярдәме түбәндәгеләр аркылы гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасында театрларны саклап калу, торгызу һәм үстерү максатларында инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

2) Татарстан Республикасында театрлар эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә булышлык күрсәтү;

3) оештырылу-хокукый рәвешләре нинди булуга карамастан, театрлар иҗади составларының (труппаларының) республика, төбәкара, гомумроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге мәдәни чараларда катнашуына ярдәм күрсәтү;

4) театрларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

5) квалификацияле белгечләрне укытуга һәм хәзерләүгә булышлык күрсәтү;

6) яңа театраль постановкалар иҗат итүгә булышу;

7) Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә торган башка чаралар.

2.Театрларга дәүләт ярдәме Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан күрсәтелә.

**7 статья. Татарстан Республикасында театрлар реестры**

1. Татарстан Республикасында дәүләт театрлары, муниципаль һәм дәүләтнеке булмаган театрлар эшли. Театрның төре һәм эшчәнлегенең профиле гамәлгә кую документларында беркетелә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә даими эшләүче театрларны исәпкә алу максатында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасында театрлар реестры (алга таба – реестр) алып барыла. Реестр белешмәләре театр сәнгатенә ярдәм итүнең һәм аны үстерүнең Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләгәндә файдаланыла.

3. Реестрны алып бару Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Реестрга дәүләтнеке булмаган театрларны кертү аларны гамәлгә куючыларның гаризалары буенча ихтыярый нигездә башкарыла.

5. Реестрдан төшереп калдыру театрның эшчәнлеге туктатылган очракта йә дәүләтнеке булмаган театрны гамәлгә куючының гаризасы буенча башкарыла.

8 статья. **Театрлар эшчәнлегенең максаты һәм төрләре**

1. Театр эшчәнлегенең максаты театр сәнгатен үстерүдән, сәхнә сәнгатенә халыкның ихтыяҗын тудырудан һәм аны канәгатьләндерүдән гыйбарәт.

2. Театр эшчәнлегенең төп төрләре түбәндәгеләр:

1) театраль тамашалар иҗат итү һәм күрсәтү, гастрольләр, концертлар оештыру, иҗат кичәләре, фестивальләр һәм конкурслар үткәрү;

2) авторлар һәм рольләрне (партияләрне) башкаручылар хокукларын граждан законнары нигезендә саклап, оешмаларның һәм гражданнарның үз мәйданнарында яисә алар тарафыннан арендага алынган мәйданнарда күрсәтү өчен, телевидениедән күрсәтү өчен, радиодан тапшыру, интернет-трансляция, кинога, фотога, видеога һәм башка матди саклагычларга төшерү өчен оешмалар һәм гражданнар белән, шартнамәчел нигездә театраль постановкалар, театраль тамашалар, башка чаралар әзерләү;

3) театраль иҗади һөнәр хезмәткәрләренә театрның әйдәп баручы осталары һәм эшлеклеләре тарафыннан стажировкалар үткәрү;

4) театраль постановкалар, театраль тамашалар кую, башка чаралар уздыру өчен оешмаларга шартнамәчел нигездә постановка хезмәтләре күрсәтү, сәхнә-постановка чаралары бирү;

5) оешмалар һәм гражданнар заказлары буенча театраль постановкаларның, театраль тамашаларның, башка чараларның сәнгати бизәлеш предметларын ясау;

6) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз сәхнә мәйданнарын гастрольләр һәм күчмә чаралар, уртак театраль проектлар һәм программалар уздыру өчен башка театрларга бирү;

7) авторлар һәм рольләрне (партияләрне) башкаручылар хокукларын гражданнар законнары нигезендә саклап, театрның сәнгати-иҗади эшчәнлегенә бәйле мәгълүмат-белешмә һәм реклама материаллары, кино-, фото-,

видеоматериаллар һәм фонограммалар әзерләү, аларны күбәйтү һәм реализацияләү;

8) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә костюмнарны, аяк киемнәрен, җайланмаларны, реквизитны, бутафорияне, гримны һәм башка әйберләрне прокатка бирү һәм реализацияләү;

9) театр чараларына билетларны реализацияләү, шулай ук тамашачыларга өстәмә хезмәтләр күрсәтү;

10) театрның һәм театраль эшчәнекнең музей фондын булдыру һәм саклау;

11) театр эшчәнлегенең предметы һәм федераль законнарда, башка норматив хокукый актларда һәм уставта билгеләнгән максатлары нигезендә театрның гамәлгә кую документларында күрсәтелгән башка эшчәнлек төрләре.

9 статья. **Театрларның хокуклары һәм бурычлары**

1. Россия Федерациясе законнары нигезендә театрлар мөстәкыйль рәвештә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) репертуарны һәм эшчәнлегенең сәнгати юнәлешен сайларга;

2) үзенең иҗади һәм хуҗалык ресурсларыннан, иҗади һәм социаль үсеш зарурлыгыннан чыгып, үз эшчәнлеген планлаштырырга һәм үсеш перспективаларын билгеләргә;

3) театр тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә һәм продукциягә бәяләр (тарифлар) билгеләргә;

4) театрның эш режимын һәм эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләргә;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

2. Театрлар үз символикаларын – гамәлгә кую документларында тасвирлана торган эмблемалар, герблар, башка геральдика билгеләре, флаглар һәм гимннар булдырырга хокуклы.

3. Татарстан Республикасында театраль тамашаларны гавами башкару һәм (яисә) гавами күрсәтү белән шөгыльләнүче театрларның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) театраль тамаша вакытында тамашачыларның гомерен һәм сәламәтлеген, шулай ук аларның саклауга тапшырылган мөлкәтен саклауны тәэмин итү;

2) билетлар сату урыннарында һәм театраль тамашаны гавами башкару һәм (яисә) гавами күрсәтү урыннарында, һәркем күрерлек итеп, тамаша нигезләнгән әсәрнең тулы исеме, авторы, куючыларның һәм төп рольләрне (партияләрне) башкаручыларның исемнәре, шулай ук театр ихтыяры буенча башка белешмәләр күрсәтелгән афиша элү;

3) театраль тамашаның үткәрелү урыны, башлану һәм тәмамлану вакыты турында, билет бәяләре, аларны алу һәм кире тапшыру шартлары хакында, аерым категориядәге тамашачылар өчен каралган ташламалар, театраль тамашага керү өчен яшь ягыннан билгеләнгән чикләүләр турында тамашачыларга мәгълүмат бирү;

4) театр билетында хезмәт күрсәтүләрнең бәясен, театрның исемен, аның оештыру-хокукый рәвешен, театраль тамашаның исемен, күрсәтелү урынын, датасын һәм вакытын, тамаша залындагы урынны күрсәтү.

4. Афишалар, башка күрсәтмә мәгълүмат текстлары Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә языла.

5. Театрлар театраль тамашаларны субтитрлар ярдәмендә яисә синхрон тәрҗемә аша Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, шулай ук башка телләрдә аңлатуны тәэмин итә ала. Гражданнарга тәкъдим ителә торган хезмәтләр турында мәгълүмат билет сатып алынганчы, театр администрациясе билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителергә тиеш.

6. Гражданнарга мәгълүмат бирү максатларында театр кассалары янында спектакльләргә билетлар булу-булмау турында актуаль мәгълүмат урнаштырыла.

### 10 статья. **Театрларга кергәндә ташламалар**

1. Түләүле чаралар оештырганда театрлар мәктәпкәчә яшьтәге балалар, укучылар, инвалидлар, чакыру буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр өчен ташламалар билгеләргә мөмкин.

Ташламалар билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы дәүләт театрлары өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, муниципаль театрлар өчен тиешле җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

3. Башка театрлар тамашачыларга спектакльләргә, концертларга һәм башка чараларга керү өчен ташламаларны мөстәкыйль билгеләргә хокуклы.

### 11 статья. **Дәүләт театрларын финанслау**

1. Татарстан Республикасында дәүләт театрларын финанслау түбәндәгеләр исәбеннән башкарыла:

1) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

2) театрларның керем китерә торган эшчәнлекне билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырудан алынган керемнәре;

3) хәйрия акчалары һәм гражданнардан, юридик затлардан алынган кире кайтарылмый торган башка керемнәр;

4) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тыелмаган башка чыганаклар.

2. Театраль эшчәнлек грантлар – гражданнар яисә юридик затлар, шул исәптән чит ил гражданнары яисә юридик затлары тарафыннан бирелүче кире кайтарылмый һәм түләтелми торган акчалар рәвешендә финанслана ала, грантлар, шулай ук, грант бирүчеләр тарафыннан каралган шартларда аерым бер иҗади проектны реализацияләү өчен бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелгән грантлар конкурс нигезендә бүленә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шул исәптән Татарстан Республикасында театр сәнгатенә ярдәм итүнең һәм аны үстерүнең дәүләт

программасын гамәлгә ашыру кысаларында бүлеп бирелә торган акчалар күләме федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

12 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт театрларының һөнәри иҗади хезмәткәрләренә аттестация үткәрү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт театрының һөнәри иҗади хезмәткәрләренә театрның сәнгать персоналы һәм театрның иҗат составы (труппа) керә. Театрның иҗат составы (труппа) турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

2. Татарстан Республикасы дәүләт театрларында эшчәнлек нәтиҗәсен арттыру, театраль постановкаларны сыйфатлы әзерләүне тәэмин итү, кадрларны рациональ сайлап алу максатында һөнәри иҗади хезмәткәрләргә аттестация үткәрелә, аттестация вакытында әлеге хезмәткәрләрнең иҗади дәрәҗәсе, һөнәри осталыклары, Татарстан Республикасы дәүләт театры эшенең перспектив һәм агымдагы планнары нигезендә киләчәктә эшләү мөмкинлекләре бәяләнә.

3. Дәүләт театрларының һөнәри иҗади хезмәткәрләренә аттестация театрда расланган Хезмәткәргә аттестация үткәрү турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм даимилектә уздырыла.

13 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

**“Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында” Татарстан Республикасы законы проектына**
**Аңлатма**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе белән төзелгән эшче төркем Татарстан Республикасында театр эшчәнлеген законнар белән җайга салу максатларында “Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында” Татарстан Республикасы законы проектын язды.

Закон проекты Татарстан Республикасының театр эше өлкәсендәге дәүләт сәясәтен, Татарстан Республикасында театрлар эшчәнлегенең нигезләрен, аларга дәүләт ярдәме чараларын билгели.

Закон проектында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының театр эше өлкәсендәге вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы арасында бүлеп бирелгән.

Татарстан Республикасы территориясендә даими эшләүче театрларның исәбен алып бару максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасында театрлар реестрын алып барылу күз алдында тотыла. Реестрдагы мәгълүматлар театр сәнгатенә ярдәм һәм аны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләгәндә файдаланылачак.

Татарстан Республикасы дәүләт театрларында эшчәнлек нәтиҗәлелеген күтәрү, театр куелышларының сыйфатлы әзерләнүен тәэмин итү, кадрларны рациональ сайлап алу максатларында һөнәри иҗади хезмәткәрләрне театрда расланган Хезмәткәрләрне аттестацияләү турында нигезләмә буенча аттестацияләү кертелә.

Закон проекты театрларның хокукларын һәм бурычларын, театр куелышлары һәм спектакльләргә билетлар булу турында тамашачаларга хәбәр итү, шулай ук аерым категорияләргә кергән тамашачылар өчен каралган ташламалар бирү тәртибен билгели.

Шулай итеп, закон проекты Татарстан Республикасында театр эше өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салуның нәтиҗәле механизмын булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

**“Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында” Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

“Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында” Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы закон актларын үз көчен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

___

**“Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында” Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

“Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында” Татарстан Республикасы законы проекты белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә финанслауны таләп итә торган нигезләмәләр кертелми.

______________________________